ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2022 г. Заинск № 629

**«2022-2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик куркынычсызлыгы программасын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 796 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Әйләнә-тирә мохитне пычратуга каршы юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген арттыру, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тирә-юньгә тискәре йогынтысын кисәтә торган чаралар комплексы уздыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**постановляет:**

1. «2022-2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик куркынычсызлыгы программасын раслау турында» (алга таба – программа) 2021 елның 28 декабрендәге 796 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, кушымталар нигезендә программаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

И.В. Гобәйдулина
(85558)3-37-47

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 13. 12.
629 номерлы карарына
1 кушымта

**«2022 - 2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлеген тәэмин итү программасы» паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022 - 2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлеген тәэмин итү программасы» |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Әйләнә-тирә мохитне саклау» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 31.03.2021 елның 31 мартындагы 507 номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>«Әйләнә-тирә мохитне саклау, Татарстан Республикасы табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану» дәүләт программасын раслау турында" 2021 елның 04 маендагы 304 номерлы карар нигезендә "Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларны яңадан торгызу һәм куллану" дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы карары. |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге |
| Программаны үтәүче | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге, "Мәгариф идарәсе" МКУ, "Яшьләр эшләре идарәсе" МКУ, Зәй муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары, предприятие, оешмалар җитәкчеләре. |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | **Төп максатлар:**<br>- экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү һәм табигать системаларын саклау<br>- тотрыклы үсешнең һәм халыкның социаль-икътисадый якланганлыгының кирәкле шарты буларак, ресурслардан рациональ һәм экологик куркынычсыз |

| | |
|---|---|
| | файдалану<br>- Зәй муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шартлар буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү<br>**Төп бурычлар:**<br>• Зәй муниципаль районы территориясендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту.<br>• Зәй муниципаль районы территориясендә өске сулыкларның сыйфатын яхшырту.<br>• Табигать комплексларын, шул исәптән урманнарны яңадан утырту һәм үсемлекләр, хайваннар дөньясының биологик төрлелеген саклау һәм торгызу.<br>• Халыкның сәламәтлеге торышын яхшырту, авыруларны киметү.<br>Калдыкларны эшкәртү һәм утилләштерү системасын кертү.<br>Зәй муниципаль районы территориясендә әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу.<br>Территорияне комплекслы бәяләүне тәэмин итү, экологик яктан имин булмаган зоналарны ачыклау, экологик иминлек өлкәсендә мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм аларга ярдәм итү.<br>Халыкның экологик культурасы системасын, гражданлык үзаңы дәрәҗәсен һәм әйләнә-тирә мохит сыйфатын тәэмин итү өлкәсендә активлыгын үстерү |
| Программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | 2022 - 2026 еллар |
| Ярдәмче программаларның исемлеге | Программа экологик һәм икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә даими төзәтелә торган конкрет ярдәмче программалар системасы аша гамәлгә ашырыла:<br>1. Техноген йөкләнешләрне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру чаралары:<br>- атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау чаралары;<br>2. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары:<br>- халыкны чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чаралары;<br>- сүүткәргеч, канализация челтәрләрен һәм корылмаларны киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү чаралары;<br>- сулыкларны төзекләндерү, ландшафтларны торгызу |

| | |
|---|---|
| | чаралары.<br>3. Җир ресурсларыннан, үсемлекләр дөньясыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау чаралары:<br>- җитештерү һәм куллану калдыкларын үтилләштерү, җыю, күмү чаралары;<br>- җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары;<br>- үсемлекләр дөньясын саклау чаралары.<br>4. Халыкны савыктыруга юнәлдерелгән чаралар;<br>5. Халыкка экологик яктан белем һәм тәрбия бирү. |
| Елларга бүлеп һәм чыганакларны күрсәтеп, финанслау күләмнәре | Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме 15554,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән елларга бүлгәндә:<br>2022 ел – 3742,8 мең сум;<br>2023 ел – 2953,0 мең сум;<br>2024 ел – 2953,0 мең сум;<br>2025 ел – 2953,0 мең сум;<br>2026 ел – 2953,0 мең сум.<br>Программаны финанслау Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зәй муниципаль районы бюджетыннан, законнар нигезендә бюджеттан тыш акчалардан шушы максатларга бүлеп бирелә торган чыганаклар булганда һәм планлаштырылган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла. Программаны бюджет финанславы күләме һәм структурасы барлык дәрәҗәдәге бюджетларның расланган параметрлары нигезендә һәм программа чараларын фактта үтәүне исәпкә алып ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Елларга бүлеп, программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре белән программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Программаның төп чараларын гамәлгә ашыру, аерым алганда, мөмкинлек бирәчәк:<br>- атмосфера һавасына техноген йөкләнешне киметергә;<br>- грунт суларының һәм туфракның пычрануын булдырмаска;<br>- предприятиеләрнең аз калдыклы, ресурсларны саклый торган технологияләргә күчүе, җитештерү һәм куллану калдыкларын, үсемлек калдыкларын урнаштыру өчен шартлар тудыруы исәбенә сәнәгать калдыклары барлыкка килүне киметергә;<br>- Зәй шәһәренең һәм авыл җирлекләренең урамнарын һәм скверларын яшелләндерергә һәм төзекләндерү чараларын гамәлгә ашырырга;<br>- әйләнә-тирә мохитне пычратуны кисәтү буенча кабул |

| | |
|---|---|
| | ителә торган чараларның оперативлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга;<br>- халык сәламәтлегенә техноген йогынты факторларын ачыкларга;<br>- халыкка экологик культура, белем бирү һәм мәгълүматлы итү дәрәҗәсен арттырырга;<br>- әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшыртырга, узган һәм агымдагы хуҗалык эшчәнлегенә бәйле экологик хәвеф-хәтәрне киметергә. |

## 1. Программа методлары белән проблеманы чишүнең башлангыч торышын анализлау һәм аны хәл итү кирәклеген нигезләү

Татарстан Республикасында җитештерү көчләренең үсеше матди һәм мәдәни байлыкның үсүенә генә түгел, ә әйләнә-тирә мохитне тагын да интенсив пычратуга һәм экологик тигезлекне бозуга да китерде. Үсә барган эксплуатация һәм табигать ресурсларын эшкәртү белән калдыклар күләме дә арта, алар табигый мохиткә кире кайта. Шуңа күрә хәзерге шартларда җәмгыять белән табигать арасындагы үзара мөнәсәбәтләр проблемасын хәл итү беренчел әһәмияткә ия.

Пычрату чыганаклары булып торак-коммуналь предприятиеләрнең, предприятиеләр һәм оешмаларның чистартылмаган коммуналь-көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, агып ята торган нефть продуктлары һәм чүп-чар тора. Канализацияле чистарту корылмалары сулыкларга чыгарыла торган суларны чистартуның заманча таләпләренә җавап бирми торган технологияләрне кулланалар. Җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый торган җитди фактор булып тора, шул ук вакытта алар - икенчел матди ресурслар чыганагы да.

Зәй муниципаль районында елына 660 мең тоннага якын калдыклар барлыкка килә. Болар - сәнәгать, төзелеш һәм биологик калдыклар, шулай ук каты көнкүреш калдыклары һәм юынтык сулар.

Сәнәгать калдыклары, каты көнкүреш калдыклары кебек үк, химик составы буенча төрле. Җир асты суларына үтеп керә ала торган һәм туфрак-үсемлек капламына тискәре йогынты ясый торган күп кенә агулы матдәләрнең югары концентрацияле сыек җитештерү калдыклары һәм юынтык сулар аеруча зур куркыныч тудыра. Калдыкларның төп массасы каты көнкүреш калдыкларының оешкан чүплекләренә чыгарыла, анда әйләнә-тирә мохит өчен яңа куркыныч матдәләр барлыкка килергә мөмкин.

Чүплектәге калдыкларның атмосферадагы явым-төшемнәр белән тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган фильтрат аеруча куркыныч санала. Фильтратта органик һәм минераль матдәләр таркалуның күп санлы компонентлары бар. Участокның гидрогеологик төзелешенә бәйле рәвештә, чүплекләрдә калдыклар күмелгәннән соң фильтрат ясалу 1 елдан 25 елга кадәр

бара. Фильтрат белән пычрануга аеруча актив су алмашы зоналары, беренче чиратта грунт сулары дучар була. Чүплек атмосфераны да, гидросфераны да агулый, үсемлек капламын һәлак итә, уңайсыз яшәү тирәлеге тудыра. Көнкүрештән агып чыккан юынтык сулар да куркыныч: аларның әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынтысын киметү барлык урбанизацияле территорияләрнең мөһим проблемасы булып тора. Куркыныч бу очракта яшәү тирәлегенең бактерияләр белән пычрануы һәм эпидемияләр кабынып китү ихтималы белән бәйле.

Сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары барлыкка килү, куллану, зарарсызландыру, саклау һәм күмү проблемаларына традицион якын килү муниципаль район халкының сәламәтлегенә зыян китерә торган, экологик тигезләнешне начарайта торган, территориянең пычрануы белән характерлана торган вәзгыятькә китерде.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә шәһәрнең сәнәгать предприятиеләре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметәчәк.

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре антропоген йөкләнешне киметү тирәлек торышында сыйфатлы уңай үзгәрешләргә һәм Зәй муниципаль районы халкының экологик иминлеген арттыруга китерәчәк.

Шәһәр халкының яшәү шартларын яхшырту, экологик мәгълүматлылык дәрәҗәсен һәм грамоталылыгын арттыру шәһәрнең тотрыклы үсеше өчен өстәмә стимул булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

## 2. **Төп максатлар һәм бурычлар, гамәлгә ашыру этаплары**

Программаның төп максатлары:

-әйләнә-тирә мохиткә чыгарылган зарарлы матдәләрне бетерүгә юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген күтәрү;

-әйләнә-тирә мохитнең сыйфатында тискәре үзгәрешләргә китерә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең начар йогынтысын кисәтә торган чаралар комплексы үткәрү.

Программаның төп бурычлары:

- шәһәр предприятиеләре тарафыннан атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруның билгеләнгән нормаларын үтәү;
- шәһәр предприятиеләре тарафыннан су объектларына зарарлы матдәләр агызуны киметү;
- су объектларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау;
- җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау;
- шәһәрдә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүне оптимальләштерү;
- шәһәрнең яшел фондын саклап калу һәм үстерү;
- шәһәр халкының уңайлы тормыш шартларын тәэмин итү;
- халыкны экологик агарту.

Программа 2022 - 2026 елларда гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары программа чараларын тәэмин

итүнең ресурс мөмкинлекләрен исәпкә ала. Бу чор әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә беренче чираттагы бурычларны хәл итәргә һәм, Зәй муниципаль районының әйләнә-тирә мохиткә һәм халык сәламәтлегенә тискәре йогынтыны булдырмау максатларында, инфраструктураны тотрыклы үстерү өчен нигез булдырырга мөмкинлек бирә.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның заказчысы булып Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

Программаны гамәлгә ашыру процессы белән идарә итү Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнгән. Программаның үтәлешен координацияләү Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләнгән. Программаны гамәлгә ашыру механизмы барлык программада катнашучыларның вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын төгәл бүлешүенә нигезләнә.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зәй муниципаль районы бюджетыннан, законнар нигезендә бюджеттан тыш акчалардан шушы максатларга бүлеп бирелә торган чыганаклар булганда һәм бирелгән средстволар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Программаны бюджеттан финанслау күләме һәм структурасы барлык дәрәҗәдәге бюджетларның расланган параметрлары нигезендә һәм программа чараларын фактта үтәүне исәпкә алып ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Программа чаралары буенча эшләрнең бәясе эшләрне башкару сметалары нигезендә билгеләнә.

## 5. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген социаль, икътисадый һәм экологик аспектларда карарга кирәк.

Икътисадый нәтиҗәгә ирешеләчәк:

-су һәм һава киңлекләренә нормадан тыш зарарлы матдәләр чыгаруны, сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын үтилләштерүнең заманча ысулларын кертү өчен түләүгә бәйле продукция җитештергәндә предприятиеләр чыгымнарын киметү аша;

-җитештерү һәм көнкүрештән чыккан җыентык суларның тирә-юньгә тискәре йогынтысын киметү аша.

Экологик нәтиҗәгә ирешеләчәк:

-әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү, аны бетерү;

-Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан торак пунктларның санитар торышын яхшырту;

-техноген һәм табигатьтә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу ихтималын киметү аша.

Социаль нәтиҗәгә ирешеләчәк:

- муниципаль район халкының сәламәтлеген яхшырту;

-әйләнә-тирә мохитнең торышы турында халыкны тагын да мәгълүматлы итү;

-программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре белән халыкның кызыксынучанлыгын арттыру;

-гражданнарның әйләнә-тирә мохит торышы турында белемнәргә тотрыклы ия булуына ихтыяҗларын гамәлгә ашыру юллары аша.

➢

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 13 12
629 номерлы карарына
2 кушымта

**6. «2022-2026 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлеген тәэмин итү программасы»
төп чаралар планы һәм көтелгән нәтиҗәләр**

| № п/п | Чаралар | Башкаручы оешма | Башкару сроклары | Финанслауның күздә тотылган чыганаклары | Финанс чыгымнарына күздә тотылган ихтыяж (мең сумнарда) | | | | | | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | барысы | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| **1. Техноген йөкләнешне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру<br>1.1. Атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау гамәлләре** | | | | | | | | | | | |
| 1.1.1 | Казаннардан газ белән атмосферага чыга торган пычраткыч матдәләрне инструментлар ярдәмендә үлчәү һәм газ чистарту җайланмасының (ГОУ) нәтиҗәлелеген лаборатор тикшерү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 770,0 | 154,0 | 154,0 | 154,0 | 154,0 | 154,0 | Атмосферага чистартмыйча зарарлы матдәләр чыгаруны булдырмау. УОГ нәтиҗәле эшләвен ачыклау |
| 1.1.2 | Регенератив һава җылыткычлары, казаннарның энергетик пар калориферлары өслекләрен юдырту | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1000,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | NOx, SO2, CO, корым, маз. ккалдыклары күләмен киметү;<br>энергия ресурсларын экономияләү |
| 1.1.3 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә, предприятие йогынтысы зонасында атмосфера һавасы торышына лаборатор контроль һәм физик факторларны үлчәү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 736,0 | 147,2 | 147,2 | 147,2 | 147,2 | 147,2 | Пычраткыч матдәләрне чыгару сәбәпләрен һәм тавышлы пычрану сәбәпләрен вакытында бетерү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.4 | КВО фильтрларын һәм полимерлаштыру камераларын алыштыру. КВО фильтрларында һәм полимерлаштыру камераларында тыгызлыгы 50 кг/м3 булган минераллы плитәләр куллану | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 9610,0 | 1770,0 | 1870,0 | 1970,0 | 2000,0 | 2000,0 | Атмосфераның потенциаль пычранган зонасын булдырмау |
| 1.1.5 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә атмосфера һавасын һәм тавыш катылыгын контрольдә тоту | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1000,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.6 | ДВОС чыганакларыннан атмосферага чыгарылган зарарлы матдәләр микъдарен үлчәү, ПЭК программасы нигезендә тикшерүләр үткәрү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 3200,0 | 1000,0 | 500,0 | 500,0 | 600,0 | 600,0 | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.7 | Пычрату чыганакларын инвентаризацияләү. НДВ эшләү. ДВОС булдыру | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 6000,0 | 2000 | 0 | 2000 | 0 | 2000 | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.8 | НМУ каршында программа буенча чаралар эшләү һәм килештерү. | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1400,0 | 300,0 | 0 | 500,0 | 0 | 600,0 | Начар һава шартларында атмосфера һавасында зарарлы катнашмаларның таралуын булдырмау |
| 1.1.9 | НМУ туганда лаборатор тикшеренүләр үткәрү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 7000,0 | 1200,0 | 1300,0 | 1400,0 | 1500,0 | 1600,0 | Начар һава шартларында атмосфера һавасында зарарлы катнашмаларның таралуын булдырмау |
| 1.1.10 | Ваграңкадан чыккан газларны яндырып бетерү системасы фильтрларын алыштыру | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 29000,0 | 5600,0 | 5700,00 | 5800,0 | 5900,0 | 6000,0 | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.11 | 1 линиядә полимеризация камерасында газларны яндырырп бетерү җиһазы монтажлау | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧЖ филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 100000,0 | 100000,0 | 0 | 0 | 0 | 0 | Атмосфера һавасына зарарлы матдәләр чыгаруны киметү |
| 1.1.12 | Фильтрлау кырларына пычраткыч матдәләр нормативларыннан артуны киметә торган «Дарсан» биоцидын кертү | «Зәй шикәре» ААЖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 12000 | 2400 | 2400 | 2400 | 2400 | 2400 | Исне, аммиак һәм күкерт водород бүленеп чыгуны киметү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.13 | Шикәр чөгендерен киптергечне проектлау | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 | Предприятиенең үз средстволары | 11000 | 11000 | | | | | Суны фильтрацияләү кырларына ташлана торган суның сыйфатын яхшырту |
| 1.1.14 | Шикәр чөгендерен киптергечне төзү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2023-2025 | Предприятиенең үз средстволары | 1000000 | | 333333 | 333333 | 333334 | | Суны фильтрацияләү кырларына ташлана торган суның сыйфатын яхшырту |
| 1.1.15 | Утырманы корыту центрифугасы сатып алу һәм урнаштыру | «Зәй шикәре» ААҖ | 2023 | Предприятиенең үз средстволары | 200000 | | 200000 | | | | Суны фильтрацияләү кырларына ташлана торган суның сыйфатын яхшырту |
| 1.1.16 | Анаэроб әчетү җайланмасын проектлау | «Зәй шикәре» ААҖ | 2025 | Предприятиенең үз средстволары | 10000 | | | | 10000 | | Суны фильтрацияләү кырларына ташлана торган суның сыйфатын яхшырту |
| 1.1.17 | Анаэроб әчетү җайланмасын төзү һәм сафка кертү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 400000 | | | | | 400000 | Суны фильтрацияләү кырларына ташлана торган суның сыйфатын яхшырту |
| 1.1.18 | Санитар-яклау зонасында һәм фильтрация кырларында атмосфера һавасы торышына химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 250,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.19 | ГОУ җиһазларына агымдагы ремонт | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.20 | ГОУ эшчәнлеге нәтиҗәлелеген контрольдә тоту | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.21 | ПДВ нормативларын үтәүне контрольдә тоту | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 250,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.22 | Автомобильләрнең агулы газ чыгаруын (төтенләвен) контрольдә тоту | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 30,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | Атмосфера һавасы торышына контроль |
| 1.1.23 | Санитар-яклау зонасы проектын эшләү | "Аккурайд Уилз Руссиа" ЖЧҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1089,0 | 1089,0 | | | | | Сәнәгать предприятиесе янында торак йортларны теркәүне булдырмау |
| 1.1.24 | Санитар-яклау зонасында атмосфера һавасын тикшерү | "Аккурайд Уилз Руссиа" ЖЧҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 109,0 | 21,8 | 21,8 | 21,8 | 21,8 | 21,8 | Нормадан тыш ташлауларны булдырмау |
| 1.1.25 | Атмосфераны пычрату чыганакларыннан чыккан сәнәгать калдыкларының сыйфатын мониторинглауны оештыру | "Аккурайд Уилз Руссиа" ЖЧҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1250,0 | 250,0 | 250,0 | 250,0 | 250,0 | 250,0 | Атмосфера һавасының нормадан тыш пычрануын булдырмау |

**2. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары**

**2.1. Халыкны чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чаралары**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.1 | Су куллану урыннарында Дала Зще елгасын һәм Зәй сусаклагычын мониторинглау | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 2500,0 | 500,0 | 500,0 | 500,0 | 500,0 | 500,0 | Су объекты мониторингын алып бару |
| **2.2. Су үткәрү, канализация челтәрләрен һәм корылмаларын киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү** | | | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | Энергоблокларда турбина май суыткычларын һәм тукландыру насосларын опрессовкалау | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 500,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Агым суларына май эләгүне булдырмау |
| 2.2.2 | Пар казаннары, турбина цехларының котельный һәм турбина бүлекләренең ян чокырларын һәм каналларын чистарту һәм ремонтлау | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 1000,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | Агым суларына май эләгүне булдырмау |
| 2.2.3 | Гидротехник корылмаларга, 1,2,3 номерлы балык саклау җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 7305,0 | 1461,0 | 1461,0 | 1461,0 | 1461,0 | 1461,0 | Су алганда Зәй сусаклагычындагы су биологик ресурсларына тискәре йогынтыны киметү |
| 2.2.4 | Хим-су әзерләү участогы фильтрларын алыштыру. | "Аккурайд Уилз Руссиа" ҖЧҖ | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 10500,0 | 1900,0 | 2000,0 | 2100,0 | 2200,0 | 2300,0 | Агымсуларны җыю, җир ресурсларын пычратуны булдырмау |
| 2.2.5 | Фильтрация кырларын ремонтлау, валларны ныгыту | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 3350,0 | 650,0 | 650,0 | 670,0 | 670,0 | 670,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.6 | Җир асты резервуарын чистартып, артскважиналарны агымдагы ремонтлау | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 225,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.7 | Фильтрация кырларын бүлү җайланмаларын ремонтлау (Д=325 мм) | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 215,0 | 40,0 | 40,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.8 | Агым суларга һәм табигый суларга химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 250,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Бөгелде елгасына мониторинг |
| 2.2.9 | Артезиан суына химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 334,0 | 65,0 | 65,0 | 68,0 | 68,0 | 68,0 | Скважиналардагы суның сыйфатына мониторинг |
| 2.2.10 | Махсуслаштырылган автомойкада автотранспорт юу | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 115,0 | 20,0 | 20,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Нефть продуктлары ташлауны булдырмау |
| **2.3. Эрозиягә каршы чаралар, сулыкларны сәламәтләндерү һәм төзекләндерү, ландшафтларны торгызу** | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3.1 | Химик күрсәткечләрне һәм токсиклыкны белү өчен табигый һәм агынты суларны лаборатор тикшерүләр | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 2572,0 | 514,40 | 514,40 | 514,40 | 514,40 | 514,40 | Пычрата торган матдәләр ташлану сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.3.2 | Кире кайта торган суны микробиологик һәм паразитологик тикшерүләр (агынты суларга производство контроле) | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 614,0 | 122,80 | 122,80 | 122,80 | 122,80 | 122,80 | Су объектына пычраткыч матдәләр һәм микроорганизмнар ташлану сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.3.3 | Су объектының яр буе линиясен чистарту буенча экологик чаралар | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ЖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 570,0 | 100,0 | 110,0 | 120,0 | 120,0 | 120,0 | Су объектына пычрату калдыклары элэгүне булдырмау |
| 2.3.4 | Балык саклау җайланмасына агымдагы ремонт | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 125,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.3.5 | Су тондыргычны чистарту һәм фильтрлау кырлары картларын сөрү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 2750,0 | 550,0 | 550,0 | 550,0 | 550,0 | 550,0 | Туфрак эррозиясен булдырмау |
| 2.3.6 | Бөгелде елгасының агынты сулары һәм өслек сулары сыйфатын тикшерү | "Аккурайд Уилз Руссиа" ЖЧҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 925,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 | Чистарту технологиясен тикшереп тору, табигый суларның пычрануын булдырмау |
| 2.3.7 | Яңа Спас авыл җирлегегенң Ирнә авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | 300 | | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.8 | Яңа Спас авыл җирлегегенң Яңа Спас авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | 300 | | Төзекләндерү |
| 2.3.9 | Яңа Спас авыл җирлегегенң Иске Бүсрәк авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | | 300 | Төзекләндерү |
| 2.3.10 | Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврин авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 350 | 350 | | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.11 | Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | 300 | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.12 | Поручик авыл җирлегенең Канаш авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | 300 | | Төзекләндерү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3.13 | Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | 300 | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.14 | Югары Налим авыл җирлегенең Налим авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | 300 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.15 | Аксар авыл җирлегенең Бүре Сарай авылында чишмә төекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | 300 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.16 | Аксар авыл җирлегенең Аксар авылында чишмә төекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | 300 | | Төзекләндерү |
| 2.3.17 | Баграж авыл җирлегенең Урта Баграж авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | 300 | | Төзекләндерү |
| 2.3.18 | Баграж авыл җирлегенең Югары Баграж авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | | 300 | Төзекләндерү |
| 2.3.19 | Мунча авыл җирлегенең Кабан Бастрык авылында чишмә төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | 300 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.20 | Поповка авыл җирлегенең Демитрово авылында чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | | 300 | Төзекләндерү |
| 2.3.21 | Бигеш авыл җирлегенең Карман авылында чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 300 | | | | | 300 | Төзекләндерү |
| 2.3.22 | Бөгелде елгасының су саклау зонасы ярларын чистарту һәм ныгыту | Башкарма комитет | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 400 | | 400 | | | | Ярларны ныгыту |
| 2.3.23 | Кармалка елгасының үзәнен чистарту һәм су саклау зонасы ярларын ныгыту | Поповка АҖ башкарма комитеты | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 500 | | | 500 | | | Ярларны ныгыту |
| 2.3.24 | Сармаш Башта ГТСны капиталь ремонтлауның проект-смета документларын эшләү | ЗМР Башкарма комитеты | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 978 | | 978 | | | | |
| 2.3.25 | Сармаш Башта ГТСны декларация алды тикшерүе | ЗМР Башкарма комитеты | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 95 | 95 | | | | | Су ресурсларын саклау |
| 2.3.26 | Сармаш Башта ГТС зыянын исәпләү | ЗМР Башкарма комитеты | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 100 | 100 | | | | | Су ресурсларын саклау |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3.27 | Тøги торак пунктында ГТСның куркынычсызлык декларациясе | ЗМР Башкарма комитеты | 2022-2026 | ЗМР бюджеты | 599 | 599 | | | | | Су ресурсларын саклау |
| **3. Җир ресурсларын, үсемлекләр дөньясын рациональ файдалану һәм саклау буенча чаралар**<br>**3.1. Җитештерү һәм куллану калдыкларын утилләштерү, туплау, күмү** | | | | | | | | | | | |
| 3.1.1 | Калдыкларны алга таба утилләштерү һәм зарарсызландыру максатында җыю буенча хезмәтләр күрсәтү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 2469,0 | 493,80 | 493,80 | 493,80 | 493,80 | 493,80 | Икенчел ресурсларга караган калдыкларны каты көнкүреш калдыклары полигонында күмүне булдырмау |
| 3.1.2 | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы ихтыяҗлары өчен калдыклар җыю һәм утилләштерү хезмәтләре күрсәтү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2022-2026 | Предприятиенең үз средстволары | 9320,0 | 1864,00 | 1864,00 | 1864,00 | 1864,00 | 1864,00 | Каты көнкүреш калдыклары полигонына чыгарыла торган калдыкларны урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә йөкләнешне киметү |
| 3.1.3 | Җитештерү калдыкларын вакытында чыгару һәм утильләштерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 60000,0 | 10000,0 | 10000,0 | 10000,0 | 10000,0 | 10000,0 | Әйләнә-тирә мохитнең җитештерү калдыклары белән пычрануын булдырмау |
| 3.1.4 | Калдыкларны инвентаризацияләү. Паспортларны рәсмиләштерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 500,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.5 | 1-4 класслы хәвефлелектәге калдыклар белән эш итүгә лицензияне яңадан рәсмиләштерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 500,0 | 500,0 | - | - | - | - | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.6 | Икенчел калдыкларны тапшыру (макулатура, резина, чүпрәк-чапрак һ. б.) | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 225,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Күмелә торган калдыкларны киметү |
| 3.1.7 | Җитештерү процессының үзгәрешсезлеге турында техник хисап | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 125,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.8 | Куркыныч калдыкларның паспортларын эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.9 | Карьерларны рекультивацияләү + тех.контроль (Поповка карьеры) Поповка авыл җирлеге | ЗМР Башкарма комитеты | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 2703 | 550 | 653 | 500 | 500 | 500 | Туфракның уңдырышлы катламын торгызу |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1.10 | Зәй шәһәре һәм Зәй районы территориясендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | ЗМР Башкарма комитеты | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 3450 | 700 | 800 | 550 | 700 | 700 | Туфракның уңдырышлы катламын торгызу |
| 3.1.11 | Калдыкларны җыю, бетерү, үтилләштерү, зарарсызландыру системасын оештыру (контейнер мәйданчыклары) | ЗМР Башкарма комитеты | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 100 | | | 100 | | | |
| 3.1.12 | Икенчел файдаланылырга тиешле калдыкларны аеру максаты белән калдыкларны селектив җыюны оештыру (батарейкалар өчен контейнерлар) | ЗМР Башкарма комитеты | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 200,0 | 100 | 100 | | | | |
| **3.2. Җир ресурсларыннан рациональ файдалану һәм саклау** | | | | | | | | | | | |
| 3.2.1 | Калдыклар белән эш итүдә җитештерү контроле тәртибен эшләү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 200,0 | 100,0 | - | 100,0 | - | - | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.2.2 | Калдыклар белән эш итүдә җитештерү контроле тәртибен эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 70,0 | | | 70,0 | | | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| **3.3. Яшелләндерү һәм үсемлекләр дөньясын саклау** | | | | | | | | | | | |
| 3.3.1 | Предприятие территориясен яшелләндерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 380,0 | 100,0 | 70,0 | 70,0 | 70,0 | 70,0 | Әйләнә-тирәлекнең пычрануын киметү |
| 3.3.2 | Предприятие территориясен яшелләндерү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2022 – 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.3.3 | Зәй шәһәре һәм районы территориясендә яшел үсентеләр сатып алу һәм утырту, агачларны санитар кисү. | ЗМР Башкарма комитеты | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 3058 | 949,8 | 500 | 503 | 553 | 553 | Әйләнә-тирәлекнең пычрануын киметү |
| **4. Экологик тәрбия, белем бирү һәм агарту эшчәнлеге** | | | | | | | | | | | |
| 4.1 | Әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча персоналның квалификациясен күтәрү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2022 - 2026 | Предприятиенең үз средстволары | 245,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 45,0 | Табигатьне саклау эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.2 | Халыкара җир көне, Экологик белемнәр көне, Урман көненә багышланган экологик акцияләр оештыру, «Эзләнү һәм казанышлар офыклары» фәнни-гамәли конференциясе, «Чиста урман», «Сыерчык оясы " экологик акцияләре | | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 50 | 50 | | | | | Табигый бергәлек системасы һәм анда кешенең тоткан урыны турында тулы бер фәнни күзаллау һәм белемнәр формалаштыру |
| 4.3 | Күрсәтмә-экологик мәгълүмати материал әзерләү | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 19 | 19 | | | | | Экологик белем күтәрү |
| 4.4 | «Эко Зәй», «Чиста шәһәр – безнең эшебез», «Йолдызлы җыештыру», «Агач утырт!», «Яшьләр- чүпкә каршы», «Ага чишмә челтер-челтер», «оБЕРЕГай», «Шәһәр елгаларына - чиста ярлар», «Яшьтән табигать турында кайгыртыйк», «Кеше булып калыйк!" экологик акцияләре | «ТР ЗМР яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2022 – 2026 | ЗМР бюджеты | 30 | 30 | | | | | Экологик белем күтәрү |
| 4.5 | 9-11 сыйныф укучыларын профильле әзерләү буенча эш | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2022 - 2026 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнарсыз | | | | | | Алынган экологик белемнәрне конкрет эш урынында, булачак һөнәри эшчәнлектә грамоталы файдалану |
| 4.6 | Мәктәп балаларына экологик белем бирү буенча авторлык программалары конкурсы уздыру | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2022 - 2026 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнарсыз | | | | | | Укучыларны һәм укытучыларны табигатьне саклау буенча иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итү |
| 4.7 | Белем бирү учреждениеләре базасында оештырылган экологик отрядларның эшчәнлеген оештыру | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2022 - 2026 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнарсыз | | | | | | Укучыларны гамәли экологик эшчәнлеккә җәлеп итү |
| 4.8 | **Муниципаль бюджет средстволары** | | | | **15554,8** | **3742,8** | **2953,0** | **2953,0** | **2953,0** | **2953,0** | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.9 | **Предприятиеләрнең үз средстволары** | | | | | | | |
| 4.10 | **Барысы** | | | | | | | |

Приложение № 3
к постановлению Исполнительного комитета
Заинского муниципального района
Республики Татарстан
от «13» 12 2022 г. № 629

## Таблица распределения денежных средств по годам и источникам

| № п/п | Наименование мероприятий | Источники финансирования | Предполагаемая потребность в финансовых затратах (тыс. руб.) | | | | | | Значения индикаторов | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Всего** | **2022 г.** | **2023 г.** | **2024 г.** | **2025 г.** | **2026 г.** | **2022 г.** | **2023 г.** | **2024 г.** | **2025 г.** | **2026 г.** |
| 1 | Ликвидация несанкционированных свалок на территории г.Заинска и Заинского муниципального района | | 3450 | 700 | 800 | 550 | 700 | 700 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 2 | Рекультивация карьеров + тех.контроль (Поповский карьер) Поповское сельское поселение | | 2703 | 550 | 653 | 500 | 500 | 500 | 1 | | 1 | 1 | 1 |
| 3 | Благоустройство родника в д.Ирня, Новоспасского сельского поселения | | 300 | 300 | | | | | 1 | | | | |
| 4 | Благоустройство родника с.Новоспасск, Новоспасского сельского поселения | | 300 | | | | 300 | | | | | 1 | |
| 5 | Благоустройство родника д.Старый Бусеряк, Новоспасского сельского поселения | | 300 | | | | | 300 | | | | | 1 |
| 6 | Благоустройство родника с.Старое Маврино, Старомавринское сельского поселения | | 350 | 350 | | | | | 1 | | | | |
| 7 | Благоустройство родника д.Светлое Озеро, Светлоозерского сельского поселения | | 300 | | 300 | | | | | 1 | | | |
| 8 | Благоустройство родника д.Канаш, Поручиковского сельского поселения | | 300 | | | | 300 | | | | | 1 | |
| 9 | Благоустройство родника с. Верхний Налим, Верхненалимское сельского поселения | | 300 | | 300 | | | | | 1 | | | |
| 10 | Благоустройство родника с. Налим, Верхненалимское сельского поселения | | 300 | | | 300 | | | | | 1 | | |
| 11 | Благоустройство родника с. Буре-Сарай, Аксаринского сельского поселения | | 300 | | | 300 | | | | | 1 | | |
| 12 | Благоустройство родника с. Аксарино, Аксаринского сельского поселения | | 300 | | | | 300 | | | | | 1 | |
| 13 | Благоустройство родника с. Средний Багряж, Багряжского сельского поселения | | 300 | | | | 300 | | | | | 1 | |
| 14 | Благоустройство родника с. Верхний Багряж, Багряжского сельского поселения | | 300 | | | | | 300 | | | | | 1 |
| 15 | Благоустройство родника д.Кабан Бастрык, Дуртмунчинского сельского поселения | | 300 | | | 300 | | | | | 1 | | |
| 16 | Благоустройство родника д.Демитрово, Поповского сельского поселения | | 300 | | | | | 300 | | | | | 1 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Благоустройство родника д.Карманово, Бегишевского сельского поселения | | 300 | | | | | 300 | | | | | 1 |
| 18 | Расчистка русла и укрепление берегов водоохраной зоны р. Бугульдинка | | 400 | | 400 | | | | | 1 | | | |
| 19 | Расчистка русла и укрепление берегов водоохраной зоны р. Кармалка | | 500 | | | 500 | | | | | 1 | | |
| 20 | Преддекларационное (регулярное) обследование ГТС в н.п.Сармаш Баш | | 95 | 95 | | | | | 1 | | | | |
| 21 | Расчет вреда ГТС в н.п.Сармаш Баш | | 100 | 100 | | | | | 1 | | | | |
| 22 | Декларация безопасности ГТС в н.п. Тюгеевка | | 599 | 599 | | | | | 1 | | | | |
| 23 | Приобретение и посадка зеленых насаждений, санитарная обрезка деревьев на территории г.Заинска и Заинского муниципального района | | 3058,8 | 949,8 | 500 | 503 | 553 | 553 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| 24 | Организация экологических акций, посвященные международным дням «День Земли», «День экологических знаний», «День леса». Научно-практическая конференция «Горизонты поиска и достижений», Эко акции «Чистый лес», «Скворечник». Награждение победителей "Эковесна" | | 50 | 50 | | | | | 1 | | | | |
| 25 | Изготовление наглядно-экологического информационного материала | | 19 | 19 | | | | | 1 | | | | |
| 26 | Организация экологических акций «Эко Зай», «Чистый город – наша работа», «Звездная уборка», «Посади дерево», «Молодежь против мусора», «Ага чишмэ челтэр-челтэр», «оБЕРЕГай», «Городским рекам - чистые берега», «С юных лет с заботой о природе», «Давайте будем людьми» | | 30 | 30 | | | | | 1 | | | | |
| 27 | **Итого:** | | **15554,8** | **3742,8** | **2953,0** | **2953,0** | **2953,0** | **2953,0** | | | | | |
| 28 | Предприятия, учреждения, организации | Собственные средства предприятий | | | | | | | | | | | |
| 29 | **ВСЕГО:** | | | | | | | | | | | | |